«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**2022 елның «_26_» декабре** **№1976**

Чистай муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының
2021 елның 29 сентябрендәге 1097 номерлы
боерыгы белән расланган җир кишәрлекләрен
милеккә түләүсез бирү хокукына ия булган
затлар буларак гражданнарны исәпкә кую
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына таянып

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 29 сентябрендәге 1097 номерлы боерыгы белән (Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының 2022 елның 8 сентябрендәге 1398 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия булган затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 2.5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать категориясенә һәм нигезенә карамастан түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (физик затларның законлы вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

3) гариза:

- документ рәвешендә кәгазьдә (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

- электрон формада (тиешле белешмәләрне электрон гариза формасына кертү юлы белән тутырыла), Регламентның 2.5.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә;

4) ата-ана никахта йә никахта тормаса, әмма бергә яшәгән очракта, ата-ана паспорты;

5) чит илнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән бала туу турында таныклык һәм аның Россия Федерациясеннән читтә бала тууын теркәү очрагында рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе;

6) үндүрт яшькә җиткән баланың паспорты (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);
7) баланы уллыкка алуны билгеләү турындагы суд карары, баланың туу турындагы таныклыкта уллыкка алучылар ата-ана буларак язылган очраклардан тыш;
8) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән күчемсез милек объектларына милектә булган торак йорт урнашкан җир кишәрлеге тапшырылган очракта хокукларны билгели торган документлар.
9) җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәрге биш ел дәвамында аның Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлүе турында тамга булмаган очракта).

3. Боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче М.Ю. Исхакова